МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ ХУҖАЛАГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

от “06” 07.2015 № 248

Казан

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә, алар дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгәндә, Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм тоту, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яйсә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

Татарстан Республикасы Прециденты<br>ның «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә, алар дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгәндә, Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм тоту, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яйсә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2015 елның 8 июнендәге ПУ-542 номерлы Указының 2 пункты нигезендә боерык бирәм:

1. Кушымта итеп бирелүче Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә, алар дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгәндә, Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм тоту, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яйсә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтке вазыйфалары исемлеген расларга.

2. Әлеге боерыкның үтәлүен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Министр Л.Р. Сафин

Татарстан Республикасы
транспорт һәм юл
хуҗалыгы министрлыгының
2015 елның 6 июлендәге
248 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә, алар дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгәндә, Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм тоту, акча һәм кыйммэтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яйсә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары
исемлеге

1. Татарстан Республикасы Преңидентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Реестры турында» 2006 елның 18 гыйнварындагы ПУ-9 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Реестрында вазыйфаларның югары торкеменә кертелгән Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгындагы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары:

министр урынбасары.

2. Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вазыйфа биләгәндә аеруча мөһим мәгълүматлар белән эшләү күздә тотылган вазыйфалары:

стратегик үстерү идарәсе башлыгы;

транспорт идарәсе башлыгы;

режим, мобилизацион әзерлек, гражданлык оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр бүлеге башлыгы;

режим, мобилизацион әзерлек, гражданлык оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр бүлеге төп белгече.